Ф. Ә. Ганиев – «татар грамматикасы, лексикологиясе һәм лексикографиясе тарихында тирән эз калдырган тел белгече, тормышын төрки татар тел белеме проблемаларын өйрәнүгә багышлаган һәм Татарстанда гына түгел, чит төбәкләрдә, илләрдә дә танылу яулаган, үз фәнни мәктәбен булдырып, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә һәм гыйльми эшчәнлекне оештыруга күп көч куйган олпат галим»[2]. Ул 1930 елның 1 августында Башкортстанның Салават районы Нәсибаш авылында дөньяга килә. Бабасы Шәяхмәт белән татар халкының күренекле язучысы һәм зур галиме Нәкый Исәнбәтнең әнисе Таибә абыстай – бертуганнар.

**Төп төшенчәләр:** тюркология, татар тел белеме, лингвистик концепция, Нәкый Исәнбәт

**Сылтама өчен:** Ганиев Ф.Ә. Нәкый Исәнбәт – тел галиме // Tatarica. 2025. № 1 (24). 7–19 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-7-19

## Кереш

Нәкый ага Исәнбәтнең эшчәнлегендә, мәгълүм булганча, борынгы кулъязмаларны өйрәнү, әдәби текстларны тикшерү шактый зур урын алып тора ([4], [5], [6], [7], [8] һ.б. – *М. Х.*) Ул шулай ук татар халык мәкальләрен һәм әйтемнәрен җыеп, классификацияләп, аларга тиешле аңлатмалар биреп, татар рухи культурасын фундаменталь хезмәтләр белән

[1] Бу мәкаләнең беренче редакциясе 1969 елда «Казан утлары» журналында басылып чыкты [1], тулыландырган варианты шул ук елны җыентыкта дөнья күрде [2]. Автор вафат булу сәбәпле, мәкаләнең структурасы, ике вариантын чагыштырып, редактор М. М. Хәбетдинова тарафыннан журнал таләпләренә туры китереп төзелде, библиографик исемлеккә төзәтмәләр кертелде.

[2] Ф. Ә. Ганиев турында *кара*: [3].

баетты ([9]). Шуның белән бергә сүзлекләр төзү эшендә дә ул актив катнашты [10], ([11] – *М. Х.*) һәм хәзерге көндә татар теленең зур аңлатмалы сүзлеген төзи[3]. Ул сүзлекнең аңлатма-проспекты СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында саклана [14].

Боларның барысы да гомуми тел белеменә, тюркологиягә, татар тел белеменә таянып эш итүне, авторда билгеле бер лингвистик концепциянең булуын таләп итәләр. Шуңа күрә дә Н. Исәнбәт эшчәнлегендә татар тел белеменә, тюркологиягә караган эзләнүләр шактый урын биләп тора. Н. Исәнбәт үзе язганча, «үксез бала үз кендеген үзе кисәр» дигәндәй, аңа бу эшләрне эшләү, ягъни тел белеменә караган теоретик проблемаларны ачыклау практик мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәк була.

Бу эзләнүләр белән беркадәр генә танышу да Н. Исәнбәтнең татар тел белеме өлкәсендә зур әзерлекле лингвист булуын һәм тел белеменең югарыда әйтелгән өлкәләрен үстерүе турында сөйлиләр.

Н. Исәнбәт үзенең хезмәтләрендә, бигрәк тә сүзлеккә караган материалларында татар теленең агглютинатив тел булуын искә төшереп, аны башка тел схемасы белән, башка тел аршыны белән үлчәмәскә чакыра. Әгәр бер телне өйрәнгәндә-тикшергәндә, аңа башка тел схемасы белән якын киленсә, ул телдәге үзенчәлекле яклар ачыкланмый кала, шул телдә булмаган күренешләр телнең кимчелеге итеп карала башлый. Шулай итеп, тел өйрәнүдәге методик кимчелек методологик кимчелеккә – вульгар социологизмга китерә.

## Материал һәм методлар

Н. Исәнбәт үзенең әсәрләрендә теге яки бу дәрәҗәдә татар теле грамматикасы мәсьәләләренә туктала. Без аның бөтен грамматик концепциясен тикшерүне үзебезнең бурыч итеп куймыйбыз. Аның грамматик карашлары хәзерге көндә зур үсеш алган грамматика фәне югарылыгында торалар. Шуның белән бергә аның грамматик карашларында татар теле грамматикасы өчен генә түгел, ә бөтен тюркология өчен дә шактый оригиналь булган фикерләр бар, һәм кайбер тел күренешләренә яңачарак килү күренә.

## Фикер алышу

Н. Исәнбәт бөр сүз төркеме итеп йөртелгән исемнәрнең шул сүз төркеменә сыешып бетмәвен күрсәтеп үтә. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә күп кенә исемнәрнең сыйфат ролендә, сыйфат булып килүен телнең бер үзенчәлеге итеп саный: «Исемнәр (сыйфат урынында килгәндә, мондый бәйләнеш аңлатмада күрсәтелеп китә: *тимер каләм (тимер* — сыйфат функциясендә)» [14, б. 20].

Тюркологиядә бу мәсьәлә буенча бердәм фикер юк: бер төр белгечләр мондый тип исемнәрне бары исем генә дип, икенче бер галимнәр исемнәрнең сыйфат ролендә килүе дип, өченче төр галимнәр исем белән сыйфатның аерылып җитмәвенең нәтиҗәсе дип карыйлар.

Исемнәрнең сыйфат булып килүләре башка телләр өчен дә чит күренеш түгел. Мәсәлән, инглиз телендә *алтын, таш, көмеш* тибындагы сүзләр шулай ук контекстка карап сыйфат мәгънәсен дә бирәләр. Инглиз теле белгечләре, германистлар моны конверсия дип, ягъни сүзнең бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчеп яңа сүз ясавы дип карыйлар.

Үзенең морфологик мәгънәсе белән киң мәгънәле булган шундый тип исемнәрне тар мәгънәгә кайтарып калдырмау, һичшиксез, телнең үзенчәлегенә туры килгән оригиналь фикер булып тора.

Н. Исәнбәтнең *лы-ле, сыз-сез* һ. б. ш. төрдәге кушымчалар турындагы карашы да зур игътибарга лаек. Тюркологиядә бу кушымчаларның грамматик һәм семантик асылы Һаман да әле анык билгеләнмәгән. Күпчелек галимнәр аларны сүз ясаучы кушымчалар рәтенә кертәләр. Мәсәлән, күренекле тюрколог профессор Н. А. Баскаков шул карашны яклый [15, б. 188–194].

Әмма тел фактлары мондый төр кушымчаларның, сүз ясау белән беррәттән, күбрәк грамматик форма ясарга сәләтле икәнен күрсәтә. Әйтик, *сез* кушымчасы *ямьсез* дигән вакытта яңа сүз, яңа лексик берәмлек ясый. Ә инде *өстәлсез калдык* дигән тезмәдәге *сез* кушымчасы бернинди дә лексик-семантик мәгънә белдерми, чөнки ул сүз аерым лексик мәгънәгә ия булган яңа бер лексик берәмлек – исем дә, сыйфат та түгел. Ул бары грамматик мәгънәне генә белдерә, ягъни «өстәл» сүзенең «сез» кушымчасы ярдәмендә ясалган формасы

[3] Н. Исәнбәтнең аңлатмалы сүзлегенең язмышы турында М. М. Хәбетдинова авторлыгындагы «Почему не был опубликован первый толковый словарь татарского языка Наки Исанбета?» мәкаләдән таныша аласыз [13].

гына булып тора. Бу күренешнең үз сәбәпләре һәм шартлары бар. Бу кушымчаларның шундый нечкә үзенчәлеге, контекстка һәм сүзенә карап, яңа лексик берәмлек тә һәм яңа грамматик форма да ясый алуын Н. Исәнбәт бик оста тотып алган, һәм ул бу турыда 1949 нчы елда ук инде болай язган: **«Лы-ле, сыз-сез** кушымчаларының кулланылуы һәр урында китерелми, бәлки мөстәкыйль мәгънәгә ия булган сүз төсен алганда гына китерелә... «җирле» сүзе үзенең морфологик төрләнеше буенча «җиргә ия», «җире бар» дигәнне белдерә, бу мәгънә морфологик төрләнеш буенча үзеннән-үзе аңлашылганлыктан, бу ягы белән аны сүзлеккә алып торуның кирәге дә юк... «өстәлсез», «чүлмәксез» һ. б. шуның шикелле гомуми тәртиптә һәр сүзгә ялгап, кушып була торган кушымчалы формалар сүзлектә урын алмыйлар» [14, б. 10].

Инде килеп 1960 нчы елда проф. М. З. Зәкиев бу мәсьәләгә тукталып, аларны, сүз ясау сәләте белән беррәттән, грамматик мәгънәләр белдерергә дә мөмкиннәр дип саный. Грамматик мәгънә тәгъбир иткәндә алар килеш формалары ясыйлар дип раслый [16]. Хәзерге татар теле белемендә бу фикер үскәннән-үсә бара.

Мәгълүм булганча, татар теленең сүзләр байлыгында кушма сүзләр, кушма лексик берәмлек зур урын тота. Мәсәлән, кушма сүзләр фигыльләрнең абсолют күпчелеген тәшкил итә. Тамыр һәм ясалма сүзләр якынча биш меңнән артмый [17, б. 14], ә кушма һәм тезмә фигыльләрнең саны исә берничә дистә меңнән артып китә. Башка төрки телләрдә дә шундый ук хәл. Ләкин ни өчендер төрки тел грамматикаларында бу күренеш бөтенләй исәпкә алынмый диярлек һәм алар сүзлекләрдә дә бирелми. Тюркологларның күбесе кушма сүзләрне, бигрәк тә кушма фигыльләрне яңа лексик берәмлек, яңа сүз дип санамыйлар, ә бары грамматик форма дип кенә карыйлар. Шундый структур типтагы кушма сүзләр, мәсәлән, һинд, япон телләрендә дә бар. Һинд һәм япон теле белгечләре аларны аерым сүз, лексик берәмлек итеп карыйлар һәм сүзлекләрдә аларны аерым мәкалә итеп бирәләр.

Н. Исәнбәт, күпчелек тюркологлардан аермалы буларак, кушма һәм тезмә фигыльләрне аерым сүз, лексик берәмлеккә кертә. Ул болай яза: «Кушма фигыльләр ике яки өч сүздән кушылып яңа мәгънә барлыкка китерү ягыннан әһәмиятле урын тоталар. Аларда саннан сыйфатка әверелеш бар. Мәсәлән, ике фигыльдән ясалган *алып килү, эчеп җибәрү, белеп калу* кебекләр. Мондый кушма фигыльләр эчендәге сүзләр кушылмыйча, аерым язылсалар да, мөстәкыйль берәр мәгънәгә ия булганлыктан, я бу сүзләр үз рәтләрендә урын алып аңлатылырга, я бер фигыль астында аерым сызык белән башланган юлларда бирелергә тиеш» [14, б. 22].

Шулай ук Н. Исәнбәт үзенең хезмәтләрендә уңышлы гына грамматик терминнар тәкъдим итә.

Мәсәлән, «фигыль наклонениесе» дип йөртелгән термин урынына «фигыль авышы», хәзерге көндәге грамматикаларда «хосусый яки препозитив кисәкчәләр» дигән термин урынына «ал кисәкчә» дигән сүз куллана.

Совет властеның беренче елларында (киң массаларны грамотага өйрәтү, культурага тарту иң актуаль һәм әһәмиятле эш була һәм шул вакытта яңа, рациональ методларга нигезләнгән әлифбалар, дәреслекләргә зур ихтыяҗ туа. Бу эштән татар укымышлыларының алдынгы вәкилләре читтә калмыйлар.

Шул чорда Н. Исәнбәт тә, укыту эшләре алып бару белән беррәттән, татар һәм башкорт мәктәпләре өчен әлифбалар, дәреслекләр төзи [18], [19], [20]. Н. Исәнбәтнең Һ. Сәгъди белән бергәләп язган башкорт әлифбасы ул вакыт өчен беренче әлифбалардан санала һәм башкорт теленең әлифбалары арасында күренекле урын алып тора. Н. Исәнбәт белән Һ. Сәгъди әлифбалары революциягә кадәрге күпчелек әлифбалардан бик нык аерыла. Бу әлифбалар рациональ методларга, тулы сүзне тоташтан уку принцибына нигезләнгәннәр. Ул чорда бу дәреслекләр мәктәпләрдә иң төп кулланмалар булып тордылар.

Н. Исәнбәт татар теленең орфография проблемалары белән күптән кызыксынып килә. Бу кызыксыну аның беренче төзегән әлифбаларыннан ук башлана.

Галим татар мәкальләрен үз эченә алган 3 томлы капиталь хезмәт бастырып чыгарды [9]. Үзенең күләме һәм эчтәлеге ягыннан бу хезмәт дөньякүләм танылган шундый мәкаль сүзлекләре белән беррәттән тора.

Китапта җыеп бирелгән мәкальләр татар рухи культурасының бай һәм күпкырлы булуын ачык күрсәтәләр. Бу гаҗәп зур һәм фундаменталь хезмәт турында кайбер мәкаләләр басылды инде. Шулай да бу хезмәт

лингвистик күзлектән чыгып тиешенчә бәяләнмәгән әле[4].

Без биредә бу эшнең тел белеменә караган кайбер моментларын искәртеп китмәкче булабыз. Җыентыкларда искиткеч күп тел байлыгы тупланган. Мәкальләрнең саны берничә дистә меңнән артып китә.

Бу хезмәттә, татар теленең структурасын, системасын, морфологик һәм синтаксик төзелешен өйрәнү-тикшерү өчен, бик бай материал тупланган. Телнең табигый төзелеше беренче чиратта мәкальләрдә чагыла. Гасырлар буена чарланып-эшкәртелеп килгән мәкальләрнең архитектоникасы татар тел төзелешенең иң нечкә үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итә. Татар теле белгечләре сүз барган җыентыклардан телнең структурасына караган чын гәүһәрләрне бик күпләп табалар һәм табачаклар. Җыеп әйткәндә, хезмәттә тупланган мәкальләр, татар теленең грамматикасын тикшерү өчен, иң ышанычлы чыганакларның берсен тәшкил итә.

Шуның белән бергә, мондагы мәкальләрнең тарихи грамматиканы өйрәнү өчен дә кыйммәте зур. Хезмәттә күп кенә мәкальләрнең якынча барлыкка килү һәм яшәеш чоры күрсәтелә. Бу исә тарихи грамматикага караган кайбер мәсьәләләрне ачыклау эшен шактый җиңеләйтә. Шулай ук мәкальләрнең эчтәлегеннән, лексик-стилистик һәм синтаксик үзенчәлекләреннән чыгып та диахроник грамматиканың күп кенә якларын күзалларга була.

Хезмәтнең лексикология һәм лексикография өчен дә әһәмияте бик зур.

Халык теленнән һәм күп төрле әдәби чыганаклардан җыелган берничә дистә мең мәкальләрдә лексиканың төрле катлавына караган бик күп сүзләр һәм фразеологик берәмлекләр табарга мөмкин: борынгы һәм тарихи сүзләр, диалекталь сүзләр, төрле-төрле алынмалар һ. б. ш. Мәкальләр эчендә хәзерге көндә телдә кулланылмаган, яисә бары борынгы истәлекләрдә һ. б. ш. гына кулланыла торган сүзләр дә очрый. Бу фактлар исә җыентыкта китерелгән мәкальләрнең сүзлекләр өчен, аерым алганда аңлатмалы сүзлек өчен, иллюстрация материалы буларак, бай хәзинә тәшкил итүен күрсәтә. Шуның белән бергә мәкальләр теге яки бу үзенчәлекле сүзнең мәгънәсен ачарга да ярдәм итә.

[4] Соңгы елларда бу сүзлеккә нигезләнеп язылган җитди хезмәтләр исемлеге белән М. М. Хәбетдинова мәкаләсендә таныша аласыз [12, 294, 305–312].

Бу хәл җыентыктагы мәкальләрнең лексикография эше өчен дә зур әһәмияте булуы турында сөйли.

Мәкальләр шулай ук борынгы һәм тарихи сүзләрнең якынча кулланылыш чорын билгеләргә мөмкинлек бирәләр һәм шуның белән бергә тарихи лексикология өчен дә бай чыганак булып торалар. Мәсәлән, *Чуртан чарыкчының утын күрмәс (чарыкчы* – төнлә чыра яндырып балык тотучы), *Ялгыз агач урман булмас, ялгыз кирпеч корган булмас (корган* – таш койма, ныгытма), *Юлдашы яхшының улҗа ләсасы яхшы (улҗа* – табыш, трофей), *Түрә сикерсә, кыргын килә (кыргын* – эпидемия).

Мондый типтагы сүзләрнең барысына да аңлатма бирелә һәм бу хәл тикшеренүченең эшен җиңеләйтә.

Җыентыкларда китерелгән мәкальләр, диалектларны, бигрәк тә диалекталь лексиканы өйрәнү өчен, үзенә бер төрле чыганак булып тора. Күпчелек мәкальләрнең кулланылу урыны күрсәтелгәнлектән, андагы сүзләрнең кайсы сөйләшкә яки диалектка каравы бик җиңел ачыклана. Җыентыкта һәр диалекталь сүзгә аңлатма бирелә. Мәсәлән, түнелү (йөз чөерү), ирмәк (күңелле, кызык), черәшү (үзсүзләнү), ырамлы (үрчемле), пыжыту (шиңдерү) һ. б. ш.

Билгеле булганча, төрле тип сүзлекләр арасында иң авыры – аңлатмалы сүзлек төзү. Бу эш, югары фәнни-теоретик хәзерлек белән беррәттән, искиткеч күп материал туплауны сорый. Аңлатмалы сүзлеккә сүзләр байлыгы һәм тиешле материал җыю өчен, бер кешедән дистәләрчә еллар буена дәвам иткән титаник хезмәт таләп итә. Н. Исәнбәт бүгенге көндә бу эшне башкарып чыккан. Ул телнең төрле чыганакларыннан энҗе бөртекләрен чүпләп җыеп, аңлатмалы сүзлек өчен искиткеч бай материал җыйган.

Сүзлеккә кертелә торган барлык төр сүзләр һәм фразеологик берәмлекләр аерым карточкаларга алынган.

Анда һәр сүзнең һәм фразеологик берәмлекнең мәгънәсе күрсәтелеп, мисаллар китерелгән һәм белешмәләр бирелгән.

Галим туплаган төрле структурадагы һәм стильдәге сүзләрнең саны 80 меңнән артып китә һәм шулай ук аның тарафыннан искиткеч бай фразеология җыйналган. Хәзерге көндә Н. Исәнбәт ул сүзлекне төзү принципларын ачыклап, карточкалардагы гаҗәеп киң материал нигезендә, аңлатмалы сүзлек төзү өстендә

эшли. Бу сүзлек үзенең төзелеше ягыннан В. Дальның иҗади үстерелгән рус теле сүзлеген хәтерләтәчәк.

Практик яктан уңайлылыкны күздә тотып, Н. Исәнбәт бу сүзлекне ныклы әлифба тәртибендә төзи. Сүзнең аңлатмасы исә иң элек хәзерге мәгънәсен бирүдән башлап, үткән заманга таба бару тәртибендә төзелә. Мәгънә аңлатмасыннан соң, аерым X абзац белән, бу сүзгә бәйләнешле тәгъбирләр, фразеология, канатлы сүзләр, идиомалар бирелә.

Аңлатмалы сүзлек 4 томда планлаштырылган[5].

Н. Исәнбәт шулай ук 1950 нче елны басылып чыккан «Татарча-русча сүзлек»не төзүдә катнашкан авторларның берсе [10].

Бу сүзлек 1950 елдан алып 1966 нчы елга кадәр киң җәмәгатьчелекнең һәм укучы массаның татарча-русча сүзлеккә булган ихтыяҗын канәгатьләндереп килде. Дөрес, сүзлекнең күләме зур түгел (20 мең сүз). Чөнки, мәгълүм булганча, ул сүзлектән, әдәби телдә яшәми дип, бик күп сүзләр төшереп калдырылган.

Шулай да бу сүзлек, лексикографик эшкәртелешнең кайбер яклары буенча, 1966 елда чыккан «Татарча-русча сүзлек»тән югары тора. Мәсәлән, 1950 нче елгы сүзлектә мисаллар, кушма лексик берәмлекләр һәм фразеологик материал аерып бирелгән, 1966 нчы елгы сүзлектәгечә [21] бергә бутап бирелмәгән. Тәрҗемәләр, нигездә, төгәл һәм конкрет.

Шуңа күрә дә бу сүзлек үзенең әһәмиятен бүгенге көнгәчә югалтмаган.

Галим әдәби әсәрләрнең текстын өйрәнү буенча да шактый зур эшчәнлек күрсәтә. Бигрәк тә аның Г. Тукай әсәрләренең җыентыклары чыгу уңае белән язылган мәкаләләре игътибарга лаек [6], [8], [22], [23]. Ул бу мәкаләләрдә Г. Тукай басмаларындагы җитди кимчелекләрне ачып салып, аларны төзәтү юлларын күрсәтә. Галимнең текстология өлкәсендәге эшчәнлеген күз алдына китерү өчен, аның Г. Тукай басмасындагы кимчелекләргә анализ бирүенә күз салу да җитә. Басмадагы текстларны лингво-стилистик тикшерү барышында Н. Исәнбәт анда күп төрле кимчелекләр таба, аларны классификацияли: шигырь калыбын һәм ритмын бозу, бер сүзне икенче сүз белән алыштыру, тыныш билгеләрен ялгыш кую, орфографик хаталар, морфологик хаталар, ялгыш аңлатмалар, хронологик хаталар һ. б. [22]. Басмадагы кимчелекләрне классификацияләп бирү үзе генә дә Н. Исәнбәтнең бик күп аналитик эш башкаруын сөйли. Н. Исәнбәт кимчелекләрне классификацияләп кенә калмый, бәлки ул кимчелекләрне конкрет фактлар китереп дәлилли. Әйтергә кирәк, галимнең дәлилләренең барысы да диярлек нигезле һәм ышандырыргыч.

Мәсәлән, Г. Тукай басмасында «кәфәштатыюш» имзасы белән бирелгән материаллар бар. Н. Исәнбәт бу имза белән китергән мәкаләләрнең Г. Тукайныкы булуы шикле дип таба. Чөнки: 1) ул мәкаләләрнең тел-стиль үзенчәлекләре Г. Тукайга туры килми; 2) бу мәкаләләрнең язылу вакыты Г. Тукайның үләр алдыннан Клячкин больницасында яту көннәренә туры килә, хәтта Тукай үлгәч тә бу имза белән «Ялт-йолт» журналында мәкалә чыга [23]. Болар барсы да Н. Исәнбәтнең текстология өлкәсендә эшләвен, тексттагы бик нечкә үзенчәлекләрне тотып ала торган галим икәнен исбатлыйлар.

Н. Исәнбәт борынгы кульъязмалар, текстлар белән күптән шөгыльләнеп килә. Ул үзенең тынгысыз археографик эзләнүләре нәтиҗәсендә байтак борынгы кульъязмалар таба һәм алар хәзерге көндә аның шәхси көтепха- нәсендә саклана. Әлбәттә, киң җәмәгатьчелек бу кульъязмалар турында галимнән тизрәк публикацияләр бирүне көтә.

Билгеле буганча, Н. Исәнбәт Казан ханлыгы чоры шагыйре Мәхмүд углы Мөхәммәдьярның «Нуры сыдур» исемле поэмасын беренче булып

[5] Нәкый Исәнбәт хәтирәләреннән: «Аңлатмалы сүзлек эшләрем үз өемә генә сыймый башлагач һәм машинкалау, редакцияләү эшләренә килеп терәлгәч, мин сүзлегемнең беренче проспектын төзеп, филиалның ишеген кактым. (Бу әле киң проспект түгел, чамаларын белү өчен алдан бирелгәне генә иде.) Һәм, татар теленең аңлатмалы тулы сүзлегемне чыгарышырга булышлык итүләрен үтенеп, филиалга мөрәҗәгать иттем. Партиянең өлкә комитеты да филиалга бу эшемдә миңа ярдәм итәргә тәкъдим иткән иде. Аннары тагын филиалда һәр галим минем белән яхшы мөгамәләдә дип әйтерлек. Күрәм: яхшы күңелле, аңлы һәм минем эшемә дә теләктәш кешеләр анда да җитәрлек.
Ләкин...» Нәтиҗәдә 1 томы китап нәшриятына тапшырылса да, сүзлек басылмый кала. Абруйлы телчеләр Л. Җәләй, Р. Газизов Н. Исәнбәт төзегән сүзлекне яклап чыктылар. Ләкин Институтның тел секторы бу эшне үз өстенә йөкли: биредә эшләгән галимнәр бу эшне бер кешегә тапшыру белән чикләнү бик зур хатага төшү булыр иде дигән фикергә киләләр. (*Кар.*: [13]).

таба. Моңа кадәр ул әсәр фәнгә бөтенләй билгеле булмый. Дөрес, Мөхәммәдьярның исеме гыйльми тикшеренүләрдә очрый. Профессор И. Н. Березин шагыйрьнең «Төхфәи мәрдан» исемле поэмасын таба һәм үзенең тикшеренүләрендә аның авторы турында кыскача мәгълүмат бирә һәм ул әсәрдән өзекләр китерә [24]. Әмма ни өчендер татар әдәбияты тарихына Н. Исәнбәт публикациясенә кадәр Мөхәммәдьяр исеме кереп китә алмый [4].

Н. Исәнбәтнең «Нуры сыдур» поэмасын табуы киң җәмәгатьчелеккә Мөхәммәдьярны яңадан ачу булып тора.

Галим бу манускриптны табу уңае белән, «Казан ханлыгы чоры әдәбиятыннан Мөхәммәдьяр Мәхмүд углы әсәрләре» дигән зур мәкалә яза [4].

Бу мәкаләдә Н. Исәнбәт поэманың авторын билгели, ул вакыттагы тарихи шартларга анализ бирә, әсәрнең төзелешен һәм телен ачыклый, мәкаләгә кушымта итеп өзекләр бирә. Әдәбият белемендә вульгар социологизм чәчәк аткан чорда Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры сыдур» әсәрен күтәреп чыгу һәм аны кыйммәтле әсәр дип билгеләү Н. Исәнбәттән үзенә күрә батырлык һәм кыюлык таләп итә. Моны билгеләп үтмичә булмый. Гомумән, Н. Исәнбәт матбугат битләрендә борынгы кулъязмаларга һәм әдәби әсәрләргә караган мәкаләләре белән әледән-әле чыгышлар ясап тора. Шундыйларга соңгы вакытта басылып чыккан «Бу шигырьнең шагыйрәсе кем?» дигән хезмәтен күрсәтергә мөмкин [4]. Монда галим Себергә җибәрелгән татар хатыны тарафыннан иҗат ителгән бер шигырь табуы турында сөйли, ул шигырьнең текстын бирә. Аның теле турында галим болай дип яза: «Казан татарларының әдәби теле XVIII гасырда һәм аннан да элек күптән формалашып килгән булуына бик матур мисалларның берсе була ала» [4, 148 б.].

Шулай ук Н. Исәнбәт 1966 елда «Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре» [25] дигән бик кызыклы мәкалә бастырып чыгара. Бу хезмәттә 1853 нче ел белән 1875 нче еллар арасында Янгилде авылында чыгарылган, анда язып алынган никрут җырлары китерелә һәм алар шактый киң тикшерелә. Шул җырларга анализ ясап, галим ул чор татар авылларының рухи тормышын бик калку итеп күз алдына китереп бастыра.

Бу җырларның характерын билгеләп, Н. Исәнбәт болай дип яза: «Шулай итеп, йөз ел элекке бу җыр дәфтәре бездә үткәндә никрутлар озату йоласы булуын, аның зур мәҗлесләр белән үзенә багышлап чыгарылган махсус наз дип аталган җыр-көйләр белән уздырылганын күрсәтә. Ихтимал ки, бу назлар башка җирләрдә дә табылса, аларны үзенә бер жанр җырлар дип тә атап була торгандыр» [25, 151 б.].

Югарыда сүз барган хезмәтләр галимнең борынгы кулъязмаларны, әдәби әсәрләрне актив җыючы, барлаучы һәм тикшерүче тынгысыз галим икәнен күрсәтәләр.

## Нәтиҗәләр

Кыска гына мәкаләдә Н. Исәнбәтнең татар филологиясе өлкәсендәге күпкырлы хезмәтенең бөтен яклары турында сөйләп бетереп булмый, әлбәттә. Әмма язучының татар филологиясенең төрле тармакларындагы югарыда күрсәтелгән эшчәнлеге дә аның киң эрудицияле, тирән белемле һәм зур эшләр күрсәткән галим-филолог булуын бик ачык исбатлый.

**Әдәбият**


1. Ганиев Ф. Исәнбәт – тел галиме // Казан утлары. 1969. №12. 122–125 б.
2. Ганиев Ф. Әдипнең татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге // Әдип һәм галим. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 74–86 б.
3. Сафина Э. И. Татар лексикографиясен яңа баскычка күтәргән галим (Фуат Ганиевнең тууына 90 ел) // Tatarica. 2020. №2 (15). 141–149 б.
4. Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры әдәбиятыннан Мөхәммәдьяр Мәхмүд углы әсәрләре // Совет әдәбияты. 1941. № 4. 68–79 б.
5. Исәнбәт Н. Хәреф һәм имлабызның гыйльми нигезләре хакында // Совет Татарстаны. 1958. 14 окт. (№ 243).
6. Исәнбәт Н. Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре // Казан утлары. 1966. № 4. 124–126 б.
7. Исәнбәт Н. Бу шигырьнең шагыйрәсе кем?: XVIII гасыр татар поэзиясе үрнәкләреннән // Казан утлары. 1967. № 1. 147–148 б.
8. Исәнбәт Н. Тукайның әлегәчә игълан ителмәгән бер шигыре // Казан утлары. 1969. № 4. 128–132 б.
9. Татар халык мәкальләре: [№ 1–38670]: 3 томда: кереш сүз һәм аңлатмалар белән / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959–1967.
10. Татарско-русский словарь = Татарча-русча сүзлек: содержит около 20 000 слов / [төз. Р. Газизов, Н. Исәнбәт, Г. Ишмухаметов]; Казан.

филиал АН СССР, ИЯЛИ. Казань: Татгосиздат, 1950. 339 с.

11. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге = Фразеологический словарь татарского языка: 2 томда / [Фәнни ред. В. Х. Хаков]. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 465 б.

12. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге = Фразеологический словарь татарского языка: 2 томда / [Фәнни ред. В. Х. Хаков]. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 495 с.

13. Хабутдинова М. М. Почему не был опубликован первый толковый словарь татарского языка Наки Исанбета? // Теория языка и межкультурная коммуникация. 2024. Выпуск 2 (53). С. 291–312.

14. Исәнбәт Н. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге (проспект). 1949. // ЦПН ИЯЛИ им. Г.Ибраһимов АН РТ. Ф.5. Оп. 19. Д. 52. 30 Л.

15. Баскаков Н. А. Каракалпакский язык. Т. 2. Фонетика и морфология. Ч. 1. Части речи и словообразование. 1952. 544 с.

16. Закиев М. З. К вопросу «категории» падежа в тюркских языках // Проблемы тюркологии и истории востоковедения. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964, С. 207–219 б.

17. Зиннатуллина К. З. Залоги глагола в современном татарском литературном языке: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. Казань, 1968. 37 с.

18. Яшь буын: Башкорт әлифбаһы / Һ. Сәгъди, Н. Исәнбәт. М.: Центр. изд. народов СССР, 1926. 64 б.

19. Яшь буын: уку китабы / Һ. Сәгъди, Н. Исәнбәт. М. : Центр. изд. народов СССР, 1926. 112.

20. Яңа мәктәп: татарча әлифба / Һ. Сәгъди, Н. Исәнбәт. Уфа : Башкнига, 1927. 72 б.

21. Татарско-русский словарь [Текст]: Около 38000 слов / АН СССР. Казан. ин-т языка, литературы и истории. Москва: Сов. энциклопедия, 1966. 863 с.

22. Исәнбәт Н. Тукайның соңгы басмасы турында // Совет әдәбияты 1945. №5. 59–73 б.

23. Исәнбәт Н. Тукайның прозасы // Совет әдәбияты 1949. №7. 102–107 б.

24. Березин И. Н. Описание турецко-татарских рукописей, хранящихся в библиотеках С-Петербурга. ЖМНП, 1846. Ч.1. отд. 3.

25. Исәнбәт Н. Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре // Казан утлары. 1966. № 11. 141–151 б.

---

# НАКИ ИСАНБЕТ – ЯЗЫКОВЕД[1]

**Фуат Ашрафович Ганиев**,
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Карла Маркса, д. 12,
m5183405@yandex.ru.

В статье Фуатом Ашрафовичем Ганиевым (1930–2016) систематизированы сведения о многогранной деятельности Наки Исанбета (1899–1992) на ниве татарской филологии, особое внимание уделяется анализу его вклада в татарское языкознание и тюркологию. Доказано, что Н. Исанбет проявил себя как талантливый ученый-филолог.

Ф. А. Ганиев – лингвист, «оставивший глубокий след в истории татарской грамматики, лексикологии и лексикографии, посвятивший свою жизнь изучению проблем тюрко-татарского языкознания и получивший признание не только в Татарстане, но и за рубежом, создавший свою научную школу, приложивший немало усилий для подготовки высококвалифицированных специалистов и организации научной деятельности»[2]. Автор статьи родился 1 августа 1930 г. в деревне Насибаш Салаватского района Башкортостана. Его дед Шаяхмет был братом Таибы абыстай, матери известного писателя и ученого Наки Исанбета.

**Ключевые слова:** тюркология, татарское языкознание, лингвистическая концепция, Наки Исанбет

**Для цитирования:** Ганиев Ф.А. Наки Исанбет – языковед // Tatarica. 2025. № 1 (24). С. 7–19. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-7-19

---

[1] Первая редакция этой статьи увидела свет в журнале «Казан утлары» («Огни Казани») в 1969 г. [1], вторая дополненная версия была опубликована в юбилейном сборнике [2]. В связи с уходом из жизни автора, структура статьи была перестроена в соответствии с требованиями нашего журнала редактором М. М. Хабутдиновой, в библиографию были внесены уточнения.

[2] *Подр. см.*: [3].